КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 8 август г.Казань № 643

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторын раслау турында» 2006 ел, 2 май, 220 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 12 февраль, 38 нче; 2007 ел, 13 июль, 297 нче; 2009 ел, 23 март, 161 нче; 2009 ел, 15 июнь, 386 нчы; 2010 ел, 22 февраль, 92 нче; 2010 ел, 9 апрель, 253 нче; 2011 ел, 6 июнь, 452 нче; 2011 ел, 27 июнь, 515 нче; 2011 ел, 8 сентябрь, 750 нче; 2012 ел, 9 февраль, 93 нче; 2012 ел, 29 март, 250 нче; 2012 ел, 8 июнь, 494 нче; 2012 ел, 19 июнь, 524 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 11 декабрь, 974 нче; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 7 июнь, 388 нче; 2014 ел, 30 август, 630 нчы; 2014 ел, 12 сентябрь, 659 нчы; 2014 ел, 30 октябрь, 823 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 3 декабрь, 940 нчы; 2015 ел, 2 февраль, 49 нчы; 2016 ел, 15 апрель, 227 нче, 2016 ел, 20 август, 578 нче; 2017 ел, 3 февраль, 58 нче; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 19 июль, 508 нче; 2017 ел, 30 ноябрь, 930 нчы; 2017 ел, 15 декабрь, 999 нчы; 2017 ел, 29 декабрь, 1118 нче; 2018 ел, 24 июнь, 586 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары функцияләре кодификаторына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

04.05.09 кодлы функция исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы карамагындагы булган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен (белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын, медицина белеме һәм фармацевтика белеме бирү программаларын, сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләреннән тыш) аттестацияләү»;

04.05.10 кодлы функция исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар эшчәнлегенә («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешнең 7 пунктында күрсәтелгән оешмалардан тыш), шул исәптән әлеге оешмаларның мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектларының инвалидлар өчен кирәклек булуын һәм мәгариф өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең алырлык булуын тәэмин итүгә, шулай ук мәгариф өлкәседә идарәне гамәлгә ашыруы җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәседә дәүләт контроле (күзәтчелеге)».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 май, 388 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1040 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 март, 195 нче; 2012 ел, 10 октябрь, 844 нче; 2013 ел, 19 март, 193 нче; 2013 ел, 18 июль, 501 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 859 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 22 октябрь, 773 нче; 2015 ел, 11 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1072 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «892,6», «640,3» саннарын тиешенчә «832,9», «567,5» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәдә:

3.1 пунктның унсигезенче һәм унтугызынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы карамагындагы булган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан муниципаль һәм хосусый оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен (белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын, медицина белеме һәм фармацевтика белеме бирү программаларын, сәнгать өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләреннән тыш) аттестацияләү (04.05.09 *);

Татарстан Республикасы территориясендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмалар эшчәнлегенә («Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешнең 7 пунктында күрсәтелгән оешмалардан тыш), шул исәптән әлеге оешмаларның мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле объектларының инвалидлар өчен кирәклек булуын һәм мәгариф өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең алырлык булуын тәэмин итүгә, шулай ук мәгариф өлкәседә идарәне гамәлгә ашыруы җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәседә дәүләт контроле (күзәтчелеге) (04.05.10 *);»;

3.2 пунктта:

ундүртенче абзацта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы спорт министрлыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

егерме тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлеген координацияләү (шул исәптән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына туры килүен тикшерүдә тоту) (02.04.01*);

республика башкарма хакимият органнары норматив хокукый актларын дәүләт теркәвенә алу (02.04.03*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән – архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.15.03*);

Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы белән –дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.07*).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин